ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

4 номерлы 2020 елның 26 феврале

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитетының
«2016-2020 елларга Иске Тимошкино авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү” муниципаль
максатчан программасын раслау турында”
**2015 елның 28 октябрендәге 15 номерлы**
карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль берәмлекнең хокукый базасын Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы таләпләренә туры китерү, “Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 27 декабрендәге 104 - ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә, программа-максатчан планлаштыру тәртибен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Уставына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитетының «2016-2020 елларга Иске Тимошкино авыл җирлеге территориясен төзекләндерү" муниципаль максатчан программасын раслау турында" **2015 елның 15 октябрендәге 12 номерлы** карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "2016-2020 елларга Иске Тимошкино авыл җирлеге территориясен төзекләндерү" муниципаль программасын раслау турында".
1.2. Программа тексты буенча "муниципаль максатчан программа" сүзләрен "муниципаль программа" сүзләренә алмаштырырга, тиешле килештә һәм санда.

2. Программага кушымта итеп бирелә торган редакция нигезендә кушымтаны бәян итеп, чаралар юнәлешләре буенча финанслау күләмнәрен бүлү өлешендә үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ru  һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Ф.Н.Степанов

Программага кушымта.

«2021- 2025 елларга авыл җирлеге территориясен төзекләндерү» муниципаль программасының төп чаралары.
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Иске Тимошкино авыл җирлеге”.

| № т/б | Чаралар | Еллар буенча чаралар үтәлеше | | | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | |
| 1 | Автомобиль юлларын һәм инженерлык корылмаларын карап тоту, торак пунктларның урамнарын кардан чистарту | 3км 30000 сум. | 3км 30000 сум. | 3км 30000 сум. | 3км 30000 сум. | 3км 30000 сум. | Финанслау күләме. Программа прогнозланган характерда һәм тиешле елга тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны финанслашуга республика һәм район бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |
| 2 | Торак пунктларның урамнарны яктырту | 3км 330000 сум | 3км 330000 сум | 3км 330000 сум | 3км 330000 сум | 3км 330000 сум | |
| 3 | Күмү урыннарын оештыру һәм карап тоту | 3 зират 10000сум | 3 зират 10000сум | 3 зират 10000сум | 3 зират 10000сум | 3 зират 10000сум | |
| 4 | Чишмәләрне төзекләндерү, данә | - | - | - | - | - | |
| 5 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, данә | - | - | - | - | - | |
| 6 | Обелискларны төзекләндерү, данә | - | - | - | - | - | |
| | Барлыгы | | | | | | |